ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

28 декабрь, 2015 ел № 5/9

Шәһәр Советының 2006 елның 6 апрелендәге 11/5 санлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге административ комиссиясенең эш Регламентына үзгәрешләр кертү турында

2013 елның 5 апрелендәге «Башкарма җитештерү турында» Федераль законга үзгәрешләр кертү хакында» 49-ФЗ Федераль законның 3 маддәсе, Татарстан Республикасының 2005 елның 30 декабрендәге «Административ комиссия төзү һәм эшчәнлеген оештыру буенча Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен муниципаль районнарның һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына тапшыру турында» 144-ЗРТ санлы Законы, шәһәр Уставының 28 маддәсе нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1. Шәһәр Советының 2006 елның 6 апрелендәге 11/5 санлы Карары (Шәһәр Советының 2007 елның 4 октябрендәне 25/18, 2007 елның 25 декабрендәге 28/14, 2010 елның 26 маендагы 50/14 санлы Карарлары редакциясендә) белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге административ комиссиясенең эш Регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Административ комиссия үз вәкаләтләрен Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары карарлары, Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Уставы, Яр Чаллы шәһәре Башкарма комитетының муниципаль хокукый актлары, башка норматив-хокукый актлар, шулай ук әлеге Регламент нигезендә башкара.»;

2) 2.1 пунктында «рәис урынбасарыннан» сүзләрен «рәиснең ике

урынбасарыннан» сүзләренә алыштырыга;

3) 3.4 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4. Административ комиссия рәисе урынбасралары комиссия әгъзалары вәкаләтләреннән файдаланалар, шулай ук административ комиссия рәисенең йөкләмәлрен үтиләр.».

4) 3.5 пунктында:

– өченче абзацта «урынбасарының» сүзен «урынбасарларының» сүзләренә алыштырырга;

– түбәндәге эчтәлектәге абзацны өстәргә:

«Җаваплы секретарь булмаган очракта, аның вазифаларын административ комиссиянең административ комиссия рәисе тарафыннан билгеләнгән бер әгъзасы башкара.»;

5) 4.13 пунктында «урынбасары» сүзен «урынбасарлары» сүзенә алыштырырга;

6) 5.4 пунктында «утыз» сүзен «алтмыш» сүзенә алыштырырга;

7) 5.7 пунктында «утыз» сүзен «алтмыш» сүзенә алыштырырга;

8) 6.1 пунктында:

– «ай саен» сүзләрен «квартал саен» сүзләренә алыштырыга;

– «Юстиция министрлыгы» сүзләрен «Министрлар Кабинеты» сүзләренә алыштырырга;

– «гаризалар һәм шикаятьләр» сүзләрен төшереп калдырырга;

9) 6.5 пунктын түбәндәге редакциядә бян итәргә:

«6.5. Административ комиссиядә килүчеләрне кабул итү гамәлгә ашырыла. Поступившие в адрес Административ комиссия адресына гражданнардан һәм юридик затлардан килгән шикаятьләр һәм мөрәҗәгатьләр гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда карала.».

2. Әлеге Карар үтәлешен тикшереп торуны Шәһәр Советының регламент, хокук тәртибе һәм халык иминлеген тәэмин итү мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев